**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“29” ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 900 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Түбән Көек авылы территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

2. Урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу.

3. Юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру.

4. Түбән Көек авылы зиратын коймалап алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү.

5. Түбән Көек авылында урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, ташу, аларны җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү)”

6. Эре мөгезле терлек өчен электрон кәтүче сатып алу.

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.